**Милләт мәшһүр адәмнәре белән мәртәбәле**

*Р.Фәхретдин*

***Укучыбыз Гөлзада***

Тормышка карыйм да сокланам,
Шатлыктан матур җыр көйлимен.
Бар бит, дип, куанам, минем дә
Үз илем, үз җирем, үз телем.
Шушы өч кыйммәткә алмашка
Һичнәрсә теләми куңелем.
Кайларга барсам да, һәрвакыт
Шулардан нур алып йөримен.

*Ш.Җиһангирова*



***Рзаева Гөлзадә Мөхәммәт кызы***

*Энергетик Мәдәният йорты директоры, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре, Чаллы шәһәре Мактаулы гражданины*

Минем шәһәрем Яр Чаллы гүзәл эшләре, кылган гамәлләре белән халыкта танылган, дистә-дистә еллардан бирле хөрмәтләре арта-үсә барган, барыбыз да горурланып шәхесләргә бай. Сүзем элек-электән шәһәребездә бердәнбер Мулланур Вахитов исемен йөртүче икенче номерлы татар мәктәбе укучысы, үзебезнең укучыбыз. Чаллы кызы Гөлзада турында. Эйе, аңа багышлап әйтеләсе әйтелгән, язылсы язылган дияргә дә мөмкин. Мин тагын нәрсә өсти алырмын икән дигән сорау да туды күңелемдә. Бу исемне ишетмәгән, үзен күреп белмәгән кеше булса да бик аздыр дип уйлыйм. Чөнки шәһәрдә ул катнашмаган берәр зуррак чара үтә микән? Аның өстенлеге дә шунда: ул ике телне дә бердәй яхшы белә. Татар мәктәбендә укуы институтларда югары белем алырга, осталык серләренә төшенергә һич тә киртә була алмады. Киресенчә, Гөлзада булачак бу катлаулы һөнәрен яшьтән үк ике телдә үзләштерә барды. Шуңа аны русы да, татары да “безнең Гөлзада” диләр бит. Тумыштан да талантлы кеше ул Гөлзада. Дөньяга талантлы булып туганнар шактый күп була, ә Ходай биргән шул бөек хәзинәне, гомер буена үстерә-баета барып, халыкка хезмәт иттерүчеләр азрак шул. Моның өчен үзеннән көчле булу, ныклык сорала. Гөлзада – сәнгать кешесе. Ул сүз сәнгате өлкәсендә хезмәт куя. Бу аеруча үзенчәлекле. Җырчыга, биючегә музыкантлар, гармунчылар ярдәмгә килә. Ә Гөлзада сәхнә уртасында ялгыз берүзе! Бары ачык, көчле тавыштан сәнгатьчә – профессиональ югарылыкта оста файдалану гына ярдәм итә аңа. Һәр сүзнең тирән мәгънәсен

аңлап, интонациясенең бөтен нечкәлекләре белән тыңлаучыларга ирештерү сәләтенә ия Гөлзада. Бу бер дә җиңел эш түгел. Шуңадыр, күрәсең, сүз сәнгате осталары – артистлар санаулы гына бит. Шушы зур шәһәребездә дә барыбыз өчен уртак Гөлзадабыз элегә берәү генә. Аның күпкырлы хезмәтләре, чиксез бай тәҗрибәсе турында ешрак язсаң да гөнаһ булмастыр.

Бик тә гыйбрәтле Гөлзада гап-гади гаиләдә туган. Әти-әнисе, тормышлары җиңелллдән булмаса да, якты дөньяга киләчәк бу унберенче баланы да бик теләп, көтеп алганнар. Гаиләнең һәр әгъзасе нәни кызчыкны бик яратып, кадерләп, аңа игътибар күрсәтергә, ярдәм итәргә тырышканнар. Бәлки, шунлыктандыр, кызчык иркәрәк үскән, бу аның төрле яктан сәләте ачылырга мөмкинлекләр дә биргәндер, күрәсең. Исеме үк Гөлзада гөл (иң матур, нәфис, гүзәлләрнең гүзәле мәгънәсендә). Кыз сылу, физик яктан да көчле, җитез чаян-кыю булып үсә. Чыныгып үсәргә ерак мәктәптә, бердәнбер татар мәктәбендә укуы да этергеч булгандыр.

Әнисе кечкенә генә төнчеген бик кызганса да, киләчәккә зур өметләр баглап, беренче класска үзе китерә. Кыска гына көзге көннәрдә дә, кышкы салкын җилләр, бураннар да, язгы мул кар сулары ташып акканда да, Гөлзада, классташлары белән бергәләр, ун ел буена һәр көн Элеватор тавыннан җәяүләп Мулланур Вахитов исемендәге урта мәктәпкә укырга йөрде. Ул вакытта бездә сәбәпсез дәрес калдырулар, соңга калулыр бөтенләй юк иде.

Бу бит үзенчә бер могъҗиза. Кыенлык-авырлыкларны җиңәргә өйрәнү, алган белемнәреңә сөенү-куану, уңышлар белән класстан класска күчә бару, һаман югарыга-камилеккә омтылу – зур җиңүләргә тиң бит ул Уку Хезмәте. Элеватор тавыннан йөреп укучыларны без аерым бер ихтирам белән “Таулар” дип йөртә идек. Менә шулай рухи һәм физик яктан чыныгып үсте безнең Гөлзадабыз. Кешегә бер генә уңыш та тырышмыенча, үзеннән-үзе генә килми. Әйе, бүген безнең Гөлзада халык тарафыннан бердәй танылган мәшһүр зат икән, ул аның гомере буе тырышып, фидакарь хезмәтләре җимеше.

...Бүгенгедәй хәтеремдә, беренче мәртәбә сәхнәгә менеп, Муса Җәлилнең “Җырларым” шигырен сөйләде Гөлзада. Бу дүртенче класста укыганда булды. Без ул елны мәктәп белән шәһәр мәдәният йортында Герой шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм улмәс иҗаты буенча әдәби-музыкаль кичәгә әзерләнә идек. “Җырларым” шигыре белән ачарга булдык. Гаҗәеп тә җаваплы эш иде бу. Ул чакта эле микрафоннар юк. Сөйләүче тавышын үз көче, осталыгы белән шыгърым тулы залга үзе ишеттерергә тиеш иде. Шуңа да миңа көчле, ачык тавышлы укучыны әзерләргә туры килде. Хөрмәтле укытучысы Анастасия Васильевна классы алдында, кыска гына итеп, мине укучысы Гөлзада белән болай таныштырды: “Тавышы җитәрлек, кычкыра инде, үзе кыю”, - диде. Минем шатлыгым эчемә сыймады. “Бер дә борчылмагыз, интонациясен үзебез өйрәнәбез”, - дигән җавабым хәзер дә исемдә. Шигырьне беренче укыгач та, максатны, кайда чыгыш ясаячакны аңлатып, баланың ризалыгын алдым. Шуннан икебез өчен дә әзерлек-сынау

башланды. Күпме хезмәт, сарыф ителгән вакыт турында үзебез генә беләбез. Өйрәнү барышындагы күп мәртәбә кабатлауларга кечкенә генә кызның түземлеге, сабырлыгына сокланып та куя идем.

...Менә Гөлзада беренче тапкыр шәһәребез мәдәният йортының зур сәхнәсендә. Бераз гына каушап киткәндәй булды кызчык. Шуңа халык шаулатып кул чапты. Гөлзадабыз “Җырларым” шигырен шулай итеп яңгыратты, зал түзмәде, аягүрә басып алкышлады. Сәхнә артында баланы үзем каршыладым. Йөзе кып-кызыл, янып-пешкән, әмма үзе бик шат иде. Ә кичәбез гадәттәгечә зур күтәренкелек, уңышлар белән узды. Ул елларда хәтта җиңүчеләргә дә бүләкләр бирү юк иде. Алкышлар, кул чабылар иң зур бүләк саналды. Олы сәнгать юлына беренче адымнары менә шулай башланды Гөлзадабызның. Алга таба, мәктәптә уку елларында, иң җаваплы чыгышлар аңа тапшырыла торган булды.

Эле Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, КамАЗ төзелеше ударнигы, Алтын йөрәкле Кеше, Бөтенроссия сәнгатькәрләре фестивале Лауреаты, Чаллы шәһәренең почетлы гражданины, Хезмәттәге батырлыгы өчен медале, Хезмәт ветераны исемнәрен алганчы аңа байтак еллар Казанда эшли-эшли укырга, булачак һөнәренең иң нечкә серләренә төшенергә-үзләштерергә, шактый еллар чын мәгънәсендә халыкка хезмәт итәргә туры килде. Сәнгать кешесе буларак, гомере буена иҗади усештә яши Гөлзада. Һәрвакыт, кайда гына булмасын, нинди генә зур залларда да әйткән һәр сүзе үткен, үтемле булуына ирешә ул. Теләсә нинди шартларда да тыңлаучылар белән уртак тел таба белә. Бу аның хезмәтендә хәлиткеч өстенлеге һәм уңышы дип уйлыйм.

“Шәһри Чаллы” газетасы битләрендә күп мәртәбәләр басылып барган “Гөлзада хитирәләре” хакында нәрсә генә әйтсәм дә аз булыр сыман. Бер караганда, алар гади генә язмалар кебек. Әмма гадилеге белән отышлы да. Бу хатирәләр туган шәһәребезнең бик тә хөрмәтле шәхесләре, кадерле, истәлекле вакыйгалары турында үткәннәребезне яңартты, шул елларга кайтып яшәдек без. Бүгенгесен тирәнрәк уйланырга, булганнынң кадерен белергә дә этәргеч булды ул.

Гөлзадабыз һәрвакыт үз мәктәбенең патриоты булды. Хәзер дә ул туган мәктәбе белән тыгыз элемтәдә яши, 2 гимназиядә оештырылган бик күп чаралар зәвык белән бизәлгән, заманча җиһазландырылган, пөхтәлеге белән күңелгә рәхәтлек бирүче "Энергетик" мәдәният сараенда үтә. гимназиянең "Соңгы кыңгырау" бәйрәме инде дистә елдан артык шушы гүзәл мәдәният йортында үткәрелә.

Күптән түгел мәктәпне 50 ел элек тәмамлаган классташлары белән очрашуны, укытучыларны чакырып, Гөлзада Мөхәммәтовна үзе оештырды.

Сәләтле кеше - Ил байлыгы, диләр. Шәһәрем горурлыгы Гөлзадабызның уңышларына барыбыз да ихластан шатланабыз. Җан азыгы булырдай яңадан-яңа ачышлар теләп калабыз.

Мулланур Вахитов исемендәге гимназия укучылары арасында хезмәтләре белән аерым игътибарга лаеклылар шактый күп. Алар һәрвакыт безнең күңелдә. Без аларны яратып, чиксез ихтирам белән искә алабыз.

Мәктәп-гимназиянең 110 елдан артык тарихында укучыбыз Гөлзаданың кабатланмас үз урыны бар.

*Ветеран укытучың А.И.Солтанова (93 яшь)*